# СИН САЗЫҢНЫ УЙНАДЫҢ

*Татар халык көе*
*НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ сүзләре*

Моңланып ай, нурларында,
Син сазыңны уйнадың;
Нинди кыллар чиртте, бәгырем,
Ул матур яшь кулларың?

Бакчаның бер почмагында
Мин утырдым, тыңладым;
Тыңладым да мин ирексез
Яшьлегемне уйладым.
    Уйладым мин яшьлегемне,
    Син сазыңны уйнадың.

Кайгылы күңелем тавында
Яңгырады кылларың.
Яңгырады ул моңлы кыллар...
Син сазыңны уйнадың.

Чыңлаган шул кылларыңдай,
Бер-бер үтте елларым:
Үтте айлар, үтте еллар,
Түзмәдем мин, егъладым
    Үтте айлар, үтте еллар,
    Син сазыңны уйнадың.

Үткән ул даулы гомерләр,
Кан — көрәштә яңгырап.
Саклаганмын тик күңелдә
Шул көрәшнең моңнарын.